ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**26.06.2018**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1341**

Муниципаль программаларны эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы нигезендә, муниципаль программаларның нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Муниципаль программаларны эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен (алга таба - тәртип) кушымтада каралганча расларга.
2. ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгы Анисимовка Д.С. әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының функциональ структурасы нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарларына йөкләргә.

Җитәкче Д.А.Сапожников

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 26 июнендәге
1341 номерлы карарына
кушымта

# Муниципаль программаларны эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип муниципаль программаларны эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү, шулай ук аларны гамәлгә ашыруның барышын контрольдә тоту кагыйдәләрен билгели.

2. Әлеге Тәртиптә түбәндәге терминнар кулланыла:

1) муниципаль программа (алга таба - Программа) - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының (алга таба – ЗМР Башкарма комитеты) җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне гамәлгә ашыру кысаларында социаль-икътисадый үсеш өлкәсендә өстенлекләргә һәм максатларга ирешүне тәэмин итүче чаралар (бурычлар, гамәлгә ашыру сроклары һәм ресурслар буенча үзара бәйләнгән)системасы ;

2) Программаның ярдәмче программасы - муниципаль программа кысаларында хәл ителә торган бурычларның масштабыннан һәм катлаулыгыннан чыгып бүлеп бирелгән максатлар, сроклар һәм ресурслар буенча үзара бәйләнгән чаралар;

3) Программаның координаторы - ЗМР Башкарма комитеты компетенциясендә әлеге Программа белән көйләү, программаны эшләү һәм гамәлгә ашыру, шулай ук аны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелгән акчаларны максатчан куллану өчен җаваплы мәсьәлә торган ЗМР Башкарма комитетының тармак (функциональ) органы.

3. Программа кысаларында Программа конкрет бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән берничә ярдәмче программадан торырга мөмкин. Программаны ярдәмче программаларга бүлү хәл ителә торган проблемаларның масштаблылыгыннан һәм катлаулылыгыннан чыгып, шулай ук аларны хәл итүне нәтиҗәле оештыру зарурлыгыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

4. Программаны гамәлгә ашыру вакыты координатор тарафыннан аны эшләү стадиясендә билгеләнә һәм 1 елдан да ким булмаска тиеш һәм 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Зеленодольск муниципаль районының социаль-икътисади үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру срогыннан артык түгел.

Муниципаль программаларны эшләү турында карарны Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнары үзләренең вәкаләтләренә ярашлы рәвештә кабул итә.

5. Программа ЗМР Башкарма комитеты карары белән раслана.

Программага үзгәрешләр кертү һәм яңа ярдәмче программаларны кертү

әлеге Тәртип нигезендә Программаның координаторы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Программаның координаторы агымдагы елның 1 августына кадәр чираттагы финанс елыннан башлап гамәлгә ашыруга тәкъдим ителә торган Программаны эшләүне тәэмин итә.

## 2 бүлек. Муниципаль программаны эшләү

6. Программаны эшләү өчен түбәндәгеләр нигез була:

- Зеленодольск муниципаль районының озак сроклы чорга социаль-икътисади үсешенең өстенлекләре һәм төп юнәлешләре белән билгеләнгән бурычлар булу;
- федераль һәм (яисә) региональ дәрәҗәдәге хокукый актларда шундый ук программалар эшләү һәм кабул итү турында тәкъдимнәр булу.

7. Муниципаль берәмлек дәрәҗәсендә программа ысуллары белән хәл итү өчен проблеманы башлап җибәрүче юридик һәм физик затлар, Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнары Программаны эшләү инициаторлары була ала. Тәкъдимнәр документлар әйләнешенең гамәлдәге кагыйдәләре нигезендә ЗМР Башкарма комитетына җибәрелә.

8. Программа проектын эшләүне Координатор гамәлгә ашыра.

9. Программаның координаторы:

1) Программа проектын эшли, аны килештерүне һәм бастырып чыгаруны тәэмин итә;

2) Программаны үз вакытында әзерләү һәм гамәлгә ашыру өчен җаваплы була, аны башкаручылар белән идарә итә, аны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган акчалардан нәтиҗәле файдалануны тәэмин итә;

3) Программаның максатларын һәм бурычларын билгели, шулай ук программа чараларын гамәлгә ашыру мониторингы өчен максатчан индикаторлар исемлеген эшли;

4) Программаны гамәлгә ашыру барышы турында әлеге Тәртип нигезендә ел саен хисап әзерли;

5) «Зеленодольск муниципаль районының контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесенә һәм «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесенә программа чараларын гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанслау күләмнәрен анализлау өчен килештерү өчен Программа проектын җибәрә;

6) Чираттагы финанс елыннан башлап гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителгән һәм агымдагы елның 1 августына кадәр яңа кертелә торган чараларны күздә тоткан Программаны эшләүне тәэмин итә;

7) Программа координаторы үз эшчәнлеге юнәлеше буенча тармак министрлыгы белән федераль максатчан программаларны, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт программаларын формалаштыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашу өчен хезмәттәшлек итә.

10. Программалар чараларын кабатлау рөхсәт ителми.

11. Чираттагы финанс елыннан башлап, финанслауга тәкъдим ителә торган

һәм яңа кертелә торган чараларны күздә тоткан Программа, Зеленодольск муниципаль районы бюджеты проекты Зеленодольск муниципаль районы Советына (алга таба – ЗМР Советы) кертелгән көнгә кадәр, 10 көннән дә соңга калмыйча, расланырга тиеш.

12. Программаны гамәлгә ашыруны финанс яктан тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме ЗМР Башкарма комитеты карарына ярашлы рәвештә, һәр Программа буенча бюджет чыгымнарының максатчан статьясы буенча ЗМР Советының Зеленодольск муниципаль районы бюджеты турында карары белән раслана.

13. Зеленодольск муниципаль районы бюджеты турында ЗМР Советы карары үз көченә кергән көннән ике айдан да соңга калмыйча, Программа аңа туры китерелергә тиеш.

## 4 бүлек. Муниципаль программаны формалаштыру

14. Программада түбәндәге позицияләр чагыла:

1) Программа паспорты, әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада каралган форма буенча;

2) аңлатма язуы, шул исәптән Программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблемаларны күрсәтеп;

3) гамәлгә ашыруның срокларын һәм этапларын күрсәтеп Программаның төп максатлары, бурычлары;

4) гамәлгә ашыру срокларын һәм җаваплы башкаручыларны күрсәтеп, программа чараларының исемлеге һәм кыскача тасвирламасы;

5) программа чаралары буенча нәтиҗәлелекне бәяләү индикаторлары;

6) Программаны ресурслар белән тәэмин итү;

7) Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү.

15. Программаның эчтәлегенә түбәндәге таләпләр куела:

1) проблемалар исемлеген чагылдыру һәм аларны нигезләү, аның барлыкка килү сәбәпләрен анализлау, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең социаль-икътисадый үсеш өстенлекләре белән бәйләнешен нигезләүне, проблемаларны шәһәр дәрәҗәсендә программалы чишүнең максатчанлыгын кертеп;

2) программа максатларының һәм бурычларының киңәйтелгән формулировкаларының эчтәлеге, Программа бурычларын хәл итү һәм куелган максатларга ирешү өчен гамәлгә ашырылырга тәкъдим ителә торган ярдәмче программалар һәм чаралар исемлеге, һәр чараны гамәлгә ашыру өчен кирәкле ресурслар турында мәгълүмат , куелган максатларга ирешү(финанслау чыганаклары кисәкләрендә) һәм сроклар, шулай ук программа чаралары буенча нәтиҗәләрне бәяләү индикаторларын күрсәтеп.

Программа максатларына куела торган таләпләр:

- үзенчәлек (максатлар Программаның координаторы компетенциясенә туры килергә тиеш);
- ирешү (максатлар потенциаль ирешелергә тиеш);
- үлчәмлелек (нәтиҗәләрне тикшерү мөмкинлеге булырга тиеш);

- билгеләнгән сроклар белән килешенгән булу  (максатка ирешү сроклары һәм тиешле максатларны билгеләп программаны гамәлгә ашыру этаплары билгеләнергә тиеш).

Куллану күрсәткечләре (индикаторлар) Программаның максатларына, бурычларына һәм чараларына ирешүне характерларга, еллар буенча планлаштырылган сан ягыннан әһәмияткә ия булырга тиеш. Программаның максатларга һәм бурычларга ирешүен характерлый торган күрсәткечләре (индикаторлар) статистик исәпкә алу күрсәткечләреннән чыгып билгеләнергә тиеш;

3) Программаның максатлары, бурычлары, чаралары буенча нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары турындагы күрсәткечләр әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтада каралганча таблица формасында китерелә;

4) еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, Программаны гамәлгә ашыру өчен кирәкле ресурс тәэмин итүне нигезләү;

5) Программаның планлаштырылган нәтиҗәлелеген бәяләүнең мәҗбүри шарты булып аны гамәлгә ашыру чорына планлаштырылган максатчан индикаторларны, шулай ук билгеләнгән срокларда чараларны тулысынча үтәү тора.

5 бүлек. Муниципаль программаларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе

16. Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү Программаның координаторы тарафыннан ел саен уздырыла.

Муниципаль программаны тормышка ашыруның барышы һәм аның нәтиҗәлелеген бәяләү турында еллык хисап (алга таба – еллык хисап) Программа координаторы тарафыннан әзерләнә һәм отчеттан соң килүче елның 1 мартына кадәр раслау өчен ЗМР Башкарма комитетына җибәрелә.

Еллык хисап ел саен 25 апрельгә кадәр, хисаптан соң килүче елның 25 апреленә кадәр «Идарә»дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасында электрон рәвештә урнаштырыла.

17.Еллык хисап әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтада күрсәтелгән формада тутырылган мәгълүматны һәм түбәндәге бүлекләрдән торган аңлатма язуын үз эченә ала:

1) хисап чорында ирешелгән конкрет нәтиҗәләр;

2) билгеләнгән срокларда үтәлгән  һәм үтәлмәгән (сәбәпләрен күрсәтеп) чаралар исемлеге;

3) Программаны гамәлгә ашыру барышына йогынты ясаган факторларны анализлау;

4)чараларны башкаруга бюджет ассигнованиеләрен һәм башка акчаларны куллану турында мәгълүмат;

5) Программаның координаторы тарафыннан муниципаль программага кертелгән үзгәрешләр турында мәгълүмат.

Программаның нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең план буенча һәм факттагы күрсәткечләре арасындагы аермалыклар булган очракта, Программа координаторы мондый чыгымнарга йогынты ясаган факторларга анализ ясый.

Анализ вакытында Программа координаторы йогынты ясый алган эчке факторлар һәм Программа координаторына бәйле булмаган тышкы факторлар аерып алына.

Программа координаторы тарафыннан Программаны гамәлгә ашыру барышы, шул исәптән программа индикаторларына ирешү һәм финанслау юнәлешләре һәм чыганаклары буенча чыгымнар турында мәгълүматның дөреслеге тәэмин ителергә тиеш.

18. Программаны гамәлгә ашыруны мониторинглау нәтиҗәләре буенча ЗМР Башкарма комитеты чираттагы финанс елына һәм план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджеты турында карар проектын керткән көнгә кадәр бер айдан да соңга калмыйча, ЗМР Советына чираттагы финанс елыннан башлап Программаны гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләрен киметү яки Программаны гамәлгә ашыруны вакытыннан алда туктату турында тәкъдимнәр кертә.

## 6 бүлек. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру белән идарә итү һәм аның үтәлешен контрольдә тоту.

19. Программа координаторы, чираттагы финанс елына Программаны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган финанс средстволарын исәпкә алып, ел саен әлеге Тәртип буенча максатчан индикаторларны, программа чараларын гамәлгә ашыруга киткән чыгымнарны, аны башкаручылар составын төгәлләштерә һәм Программаны билгеләнгән тәртиптә раслау турындагы норматив хокукый актка тиешле үзгәрешләр кертә.

20. Программага яңа ярдәмче программалар кертү һәм аларны раслау Программаны эшләү һәм гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Муниципаль программаларны эшләү, гамәлгә ашыру
һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә
1 нче кушымта

Форма

## Муниципаль программа паспорты

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Программа атамасы | | | | | |
| Программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы) | | | | | |
| Программаның төп эшләүчеләре | | | | | |
| Программаны башкаручылар | | | | | |
| Программаның максаты: | | | | | |
| Программаның бурычлары | | | | | |
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары | | | | | |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
| | | 1 ел | 2 ел | n + 1 ел | Тормышка ашыру чорында барлыгы |
| | Муниципаль бюджет | | | | |
| | Федераль бюджет | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Республика бюджеты | | | | |
| | Башка чыганаклар | | | | |
| | Барлыгы | | | | |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | | | | | |
| Программаны тормышка ашыруны контрольдә тотуны оештыру системасы | | | | | |

Муниципаль программаларны эшләү, гамәлгә ашыру
һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә
2 нче кушымта

Форма

## Муниципаль программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау

| Максатның атамасы | Бурычның атамасы | Ярдәмче программаның исеме | Төп чаралар исемнәре | Башкаручылар | Төп чараларны гамәлгә ашыру сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | база елы | 1 ел | 2 ел | n-нче ел | 1 ел | 2 ел | n-нче ел |

Муниципаль программаларны эшләү, гамәлгә ашыру
һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә
3 нче кушымта

Форма

| | |
|---|---|
| Муниципаль программа реквизитлары, тормышка ашыру чоры | |
| Муниципаль программаны раслау турында норматив хокукый актның исеме | |
| Форманы төзү өчен җаваплы вазыйфаи зат<br>(Ф. И.Ат.и., вазыйфасы, элемтә өчен телефоны) | |

## 20_ елда муниципаль программаны гамәлгә ашыру турында хисап

| № т/б | Программаның (ярдәмче программаларның) (бүлекнең, чаралар)исеме | Финанслау чыганагы (барлыгы, шул исәптән Россия Федерациясе бюджеты, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет) | Хисап елына планлаштырылган финанслау күләме, мең сум. | Хисап елына муниципаль программа буенча бүлеп бирелгән (лимит), мең сум | Фактта хисап елы өчен акча файдаланыл-ган, мең сум | Индикатор исеме | Индикатор күрсәткечләре | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | узган ел | | агымдагы ел | | | киләсе елга план |
| | | | | | | | план | факт | план | факт | үтәлү проценты | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Муниципаль программа буенча барлыгы | | Барлыгы | | | | | | | | | | |
| | | Россия Федерациясе бюджеты | | | | | | | | | | |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | | | | | | | | | | |
| | | җирле бюджет | | | | | | | | | | |